**КАРАР**
**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлеге Иске Казиле авылында гражданнарга үзара салым кертү турында**

20 нче декабрь 2022 ел № 7

"Россия Федерациясендә җирле узидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 121-ФЗ номерлы Федераль законнын 25,1, 56 статьялары, "Татарстан Республикасында җирле узидарә турында" 2004 елнын 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Иске Казиле авылында гражданнар җыены **карар итте** :

1. 2023 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Иске Казиле авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, көндезге формада укучы студентлар, олешчэ мобилизациядэ булганнар хэм аларнын гаилэ эгьзаларыннан тыш һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәгеләрне үтәү буенча юнәлтергә:

1) торак пунктта юл-урам челтәрен төзекләндерү (вак таш сатып алу, ташу, салу, килешү буенча эш өчен түләү);
2) юлларны кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
3) җәйге вакытта территорияне чабу (ротация чапкычының запас частьләрен сатып алу-2,1, ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
4) торак пункт территорияләрен төзекләндерү (Иске Казиле авылына Стелла ясау һәм урнаштыру (килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);
5) Торак пунктта янгын гидрантларын тэртиптэ тоту (янгын гидрантларын, краннарны (җайланмаларны) кышка җылыту, люкларны кардан, боздан даими чистарту, язгы-җәйге янгын куркынычы чорына әзерлек һәм тикшерү, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү)
6) урам утларын карау (материаллар, электр җиһазлары һәм компонентлар сатып алу)
7) Күмү урыннарын карап тору.(чүкеч сатып алу).

3. Әлеге карарны Иске Казиле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Кама Тамагы муниципаль

районының рәсми сайтында, хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru), кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә бастырып чыгарырга (https://kamskoye-ustye.tatarstan.ru/).

Халык җыенында рәислек итүче ,
Татарстан Республикасы Кама
Тамагы муниципаль районы
Иске Казиле авыл җирлеге башлыгы: И.Х.Сагьдиев